КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2021 ел, 28 сентябрь

г.Казань

№ 918

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 22 гыйнвар, 22 нче; 2005 ел, 30 май, 239 нчы; 2006 ел, 2 октябрь, 490 нчы; 2007 ел, 6 апрель, 123 нче; 2008 ел, 8 сентябрь, 640 нчы; 2010 ел, 29 ноябрь, 956 нчы; 2011 ел, 21 июнь, 496 нчы; 2011 ел, 6 декабрь, 1001 нче; 2012 ел, 13 апрель, 304 нче; 2013 ел, 19 гыйнвар, 20 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 8 февраль, 80 нче; 2014 ел, 5 декабрь, 947 нче; 2015 ел, 15 апрель, 254 нче; 2015 ел, 1 декабрь, 911 нче; 2016 ел, 22 июнь, 425 нче; 2016 ел, 10 сентябрь, 625 нче; 2016 ел, 20 декабрь, 959 нчы; 2017 ел, 10 май, 268 нче; 2017 ел, 28 август, 604 нче; 2017 ел, 27 октябрь, 812 нче; 2017 ел, 1 ноябрь, 833 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче; 2019 ел, 7 март, 163 нче; 2019 ел, 5 август, 644 нче; 2019 ел, 10 декабрь, 1131 нче; 2020 ел, 2 июнь, 461 нче; 2020 ел, 11 сентябрь, 827 нче; 2020 ел, 5 ноябрь, 999 нчы; 2020 ел, 16 декабрь, 1141 нче; 2021 ел, 12 июль, 567 нче; 2021 ел, 13 август, 713 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8. Хезмәт ветеранына айлык акчалата түләүне билгеләү өчен уртача айлык керем аның айлык акчалата түләүне билгеләү турында гариза бирә торган ай алдыннан алты календарь айга кадәр килгән соңгы 12 календарь айга (алга таба – исәп-хисап чоры) керемнәре суммасыннан чыгып исәпләнә.

2.10[1] пункт үз көчен югалткан дип танырга;

2.11 пунктның икенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

9.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.8. Юл йөрүгә айлык акчалата түләүне билгеләү өчен уртача айлык керем юл йөрүгә айлык акчалата түләүне билгеләү турында гариза бирә торган ай алдыннан алты календарь айга кадәр килгән соңгы 12 календарь айга (алга таба – исәп-хисап чоры) керемнәр суммасыннан чыгып исәпләнә.»;

9.10[1] пункт үз көчен югалткан дип танырга.

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарның авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче кайбер категорияләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләргә түләү буенча социаль ярдәм чараларын күрсәтү тәртибен раслау турында» 2005 ел, 7 июнь, 251 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 5 сентябрь, 432 нче; 2007 ел, 5 февраль, 35 нче; 2008 ел, 29 май, 344 нче; 2010 ел, 29 ноябрь, 961 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 13 февраль, 83 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче; 2019 ел, 13 март, 181 нче; 2020 ел, 23 ноябрь, 1053 нче; 2021 ел, 3 февраль, 47 нче; 2021 ел, 20 февраль, 92 нче; 2021 ел, 10 май, 322 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданнарның авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче кайбер категорияләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләргә түләү буенча социаль ярдәм чараларын күрсәтү тәртибенә, 11[1] пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«11[1]. Субсидия-ташлама бирү, гариза бирүченең торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурычы булганда, барлыкка килгән бурычны каплаганга яки алучы тарафыннан бурычны каплау буенча килешү төзегәнгә һәм (яки) аны үтәгәнгә кадәр туктатыла.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» 2006 ел, 24 март, 126 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 3 июнь, 370 нче; 2009 ел, 6 апрель, 203 нче; 2012 ел, 23 февраль, 153 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 25 август, 611 нче; 2015 ел, 23 сентябрь, 701 нче; 2015 ел, 1 декабрь, 911 нче; 2016 ел, 22 июнь, 425 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 998 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче; 2019 ел, 11 март, 168 нче; 2019 ел, 13 март, 181 нче; 2019 ел, 20 декабрь, 1173 нче; 2020 ел, 2 июнь, 461 нче; 2020 ел, 5 ноябрь, 999 нчы; 2020 ел, 16 декабрь, 1141 нче; 2021 ел, 20 февраль, 92 нче; 2021 ел, 10 май, 322 нче; 2021 ел, 12 июль, 567 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.3[1] пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3[1]. Хезмәт ветеранына субсидия-ташлама билгеләү өчен уртача айлык керем аның субсидия-ташлама билгеләү турында гариза бирә торган ай алдыннан алты

календарь айга кадәр килгән соңгы 12 календарь айга (алга таба – исәп-хисап чоры) керемнәре суммасыннан чыгып исәпләнә.»;

дүртенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

2.4 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия-ташлама бирү, торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурычы булган очракта, барлыкка килгән бурычны каплаганга яки алучы тарафыннан бурычны каплау буенча килешү төзегәнгә һәм (яки) аны үтәгәнгә кадәр туктатыла.».

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү өчен кертем түләү чыгымнарын компенсацияләү турында» 2018 ел, 22 август, 680 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 10 декабрь, 1105 нче; 2019 ел, 13 март, 181 нче; 2020 ел, 2 июнь, 461 нче; 2020 ел, 16 декабрь, 1141 нче; 2021 ел, 20 февраль, 92 нче; 2021 ел, 10 май, 322 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү өчен кертем түләү чыгымнарын компенсацияләү тәртибе турындагы нигезләмә, 2.8 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Компенсация бирү, гариза бирүченең торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурычы булган очракта, барлыкка килгән бурычны каплаганга яки алучы тарафыннан бурычны каплау буенча килешү төзегәнгә һәм (яки) аны үтәгәнгә кадәр туктатыла.».

5. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

бу карардагы 1 пункт, 3 пунктның икенче – бишенче абзацлары гамәле 2021 елның 1 августыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла;

бу карардагы 2 пункт, 3, 4 пунктның алтынчы, җиденче абзацлары гамәле 2021 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Премьер-министр А.В.Песошин